КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2026 ел, 4 июнь

г.Казань

№ 773

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 23 август, 690 нчы карары белән расланган Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы Рәисе грантлары бирү буенча конкурс үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 23 август, 690 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 22 ноябрь, 1037 нче; 2025 ел, 28 гыйнвар, 37 нче; 2026 ел, 4 март, 163 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм

ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы Рәисе грантлары бирү буенча конкурс үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«грантлар бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен «Коммерциягә карамаган сектор өчен цифрлы карарлар порталы белән идарә итү программасы» электрон исәпләү машиналары программасын (алга таба – Конкурс процедураларын үткәрү платформасы) куллану хокукын алу.»;

1.5 пунктның дүртенче абзацында «егерме беренче» сүзләрен «егерме икенче» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта:

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

бишенче һәм алтынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коммерциягә карамаган оешмалар өчен Конкурс процедураларын үткәрү платформасында грантлар бирүгә заявкалар формалаштыру буенча консультацияләр оештыру – кимендә 60 консультация;

экспертлар өчен Конкурс процедураларын үткәрү платформасында коммерциягә карамаган оешмаларның грантлар бирү турындагы заявкаларына экспертизалар үткәрү буенча консультацияләр оештыру – кимендә 20 консультация;»;

1.9 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс процедураларын үткәрү платформасын кулланырга;»;

5.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучы тарафыннан Конкурс процедураларын үткәрү платформасын куллану хокукын раслый торган документ;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин